МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

____10.08.2023____ Казан ш. № ____2161-р_____

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 16.11.2020 № 3495-р карары белән расланган 2021 елга салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә үзгәреш кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясының 7 пунктына, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының $1^1$ статьясына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.86 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган

күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелергә һәм электрон рәвештә салым органнарына җибәрелергә тиешле мәгълүматлар составын һәм әлеге исемлекне формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында” 2014 елның 21 ноябрендәге № 896 карары белән расланган Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелергә һәм электрон рәвештә салым органнарына җибәрелергә тиешле мәгълүматлар составын һәм әлеге исемлекне формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибенең 6 пунктына, Татарстан Республикасы Югары судының 2023 елның 28 февралендәге № 3а-169/2023 административ эше буенча карарына нигезләнеп:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 16.11.2020 № 3495-р карары белән расланган, үзләренә карата 2021 елга салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә (алга таба – Исемлек) (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 04.12.2020 № 3814-р, 26.12.2020 № 4184-р, 30.12.2020 № 4343-р, 27.07.2021 № 2267-р, 30.09.2021 №2962-р, 15.12.2021 № 3840-р, 15.12.2021 № 3845-р, 24.11.2021 № 3605-р, 04.02.2022 № 300-р, 25.04.2022 № 1273-р, 07.09.2022 № 2658-р, 12.01.2023 № 35-р, 21.02.2023 № 456-р, 13.04.2023 № 985-р, 08.06.2023 № 1544-р карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) 145 пунктны төшереп калдырып, үзгәреш кертергә:

2. Үзгәрешләр исәпкә алынган Исемлекне электрон формада Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**